# «Итәкле кияү» спектакле.

1 апрель көнне Бәзәкә мәдәният йортында зур, матур тамаша булып узды. Мәдәният йортының театр коллективы халыкка Аманулланың “Итәкле кияү” спектаклен карарга тәкъдим итте. Авыл үзешчәннәре үз рольләрен зур тырышлык һәм осталык белән, җиренә җиткереп башкардылар. Тамашачы артистларның чыгышын көчле алкышларга күмде. Рольләрне башкаручы авылдашларыбыз Фәйрүзә Хузиахметова, Фәрит Гараев, Рәфис Сибгәтуллин, Расим Мусин, Илсур Хузиахметовларга зур рәхмәтебезне җиткерәбез. Рәвия һәм РезидәМусиналар, Тәнзилә Сибгәтуллина артистларыбызга төрле яклап ярдәм күрсәтеп тордылар.Аларга һәм спектакльнең декорациясен әзерләгән Сәетҗан Ибатуллинга, банерларны әзерләүдә ярдәм күрсәткән Рәфис Закировка да рәхмәтләребезнең зурысы яусын! Менә шулай бердәм булып, ярдәмләшеп яшәгәндә, эшләр дә уңа, яллар да күңелле уза. Әфарин, бәзәкәлеләр!!!

“Узәкләштерелгән клублар системасы” директоры Рәйхәнә Ситдиковна Фәрхетдинова, узешчән артистларыбызга җылы рәхмәт сүзләрен җиткереп, таетр коллективына рәхмәт хаты тапшырды. Авылның мәдәни тормышын үстерүдә зур өлеш керткән өчен, Фәймә Галимованы һәм Сәетҗан Ибатуллинны матур юбилейлары белән котлап, рәхмәт хаты белән бүләкләде.

Театр сәнгатен сөюче үзешчән артистларыбызга киләчәктә дә зур уңышлар, биек үрләр, рәхмәтле тамашачылар телибез. Халыкка хезмәт иткәнегез өчен, Сезне Аллаһ үзе зурласын, Амин!!!

Г.Гумерова.





“Яле шаккаттарыгыз әле , тамашачыны!)))”



-Әйдә шушында гына, аллага тапшырыйк)))...



“Эх, калым түләрлек акчам булса, өйләнер идем мени мин татарга! Кая безнең үзебезнең узбечкалар!((((((...”



“Эйдә бер ящик коньякка бәхәсләшәбез!”...



“Исәнмесез, мадам!”...



“Син дә монда мени???((((”...



“Мин тыныч кына, песи кебек кенэ...мырррр)))”...



“Карбыз да усми бит монда....((((”



“Менә шулай барырга кирәк, кызлар янына, юньсезләр!...”



“Гөмерем буе шундый хатын-кыз турында хыялландым!)))...”



Артистларыбыз, молодцы 5+!!!





“Браво!!!”





“Әфарин!!!”

